РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д 8, с.Карамалы,
Азнакаевский муниципальный район
423301

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАРАМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 8 нче йорт, Карамалы
авылы, Азнакай муниципаль районы,
423301

Тел./факс(885592)4-56-42; E-mail:Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2019 ел № 45

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Карамалы авылының Яшел ур. 1 йорттан 7 йортка кадәр, Яшьләр ур. 11 йорттан 58 йортка кадәр, Профсоюз ур.2 йорттан 31 йортка кадәр, Совет ур. 1 йорттан 65 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен, 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Карамалы авылының Төзүчеләр ур. 1 йорттан 33 Б йортка кадәр, Үзәк ур. 1 йлоттран 37 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен, 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- - гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 14 ноябрь 2019 ел 10.00 сәг.тән 17.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 21 ноябрь 2019 ел 10. 00 сәг.тән 17.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Карамалы авылы, Карамалы авылы мәдәният йорты залы;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 05 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Карамалы авылы, Үзәк урам,8 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Карамалы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Карамалы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләү билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Карамалы авылы Совет, Профсоюз урамнары буенча юлларга вак таш (щебенка) җәю (таш сатып алу, таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Карамалы авылы урамнары исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу (әзерләү);
- Карамалы авылында урамнарына яктырткычлар, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешүе буенча эш өчен түләү;
- Карамалы авылында юлларны кардан чистарту;
- Карамалы авылында җәйге вакытта территорияне чабу;
- Карамалы авылында «Сабантуй» бәйрәм чарасын оештыру һәм үткәрү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Карамалы авылы, Узэк ур., 8й.

3. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

.

Башлык А.Р. Ногманов